ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

№ 5 1 ноябрь 2022 ел

«Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Татар Сөнчәлесе авылында үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 12 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Татар Сөнчәлесе авылы, Тукай урамы, 12 нче йорт адресы буенча Татсунче авыл клубында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Татар Сөнчәлесе авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслау:
I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2023 елда Аксубай муниципаль районының Мюд авыл җирлеге Татар Сөнчәлесе авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчалар җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә ризамы:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

* Татар Сөнчәлесе авылы торак пунктында юлларга вак таш сатып алу.

* * кышкы чорда Татар Сөнчәлесе авылы торак пункты чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту ,килешү буенча эш өчен түләү)

Каты көнкүреш калдыкларын җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:

• контейнерлар сатып алу

Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы-җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү

* Татар Сөнчәлесе авылы территориясендә үсентеләрне чабып алу (килешү буенча эш өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны авыл җирлегендә халык күплəп җыела торган урыннарда, белдерү такталарында һәм стендларда элү юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

4. Әлеге карар бастырылган көннән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т.В. Зюзина